РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН НАРАТБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

20 декабрь 2022 ел

№ 64-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Түбән Наратбаш авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзү
кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советының 2013 елның 18 февралендәге 1-36 номерлы карары белән расланган Түбән Наратбаш авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (28.06.2016 № 15-3, 20.09.2016 № 20-1, 23.09.2017 № 38-1, 12.02.2019 № 64-1, 22.06.2021 № 23-1, 04.05.2022 № 47-1, 08.07.2022 № 51-1, 24.10.2022 № 61-1 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Кагыйдәләрнең IX бүлегенең 30 статьясындагы 1 пунктын үзгәртергә һәм киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Ж1. Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы.

Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы Ж1 җирле әһәмияткә ия хезмәтләрнең минималь рөхсәт ителгән җыелмасы белән аерым торган һәм блокланган индивидуаль торак йортлардан (коттеджлардан) торак районнар формалаштыруның хокукый шартларын тәэмин итү өчен бүлеп бирелгән.

Күчемсез милекне файдалану рөхсәт ителгән төп төрләре:
- йорт алды җир кишәрлекләре белән индивидуаль торак йортлар;
- кишәрлекләре булган блокланган бер гаилә йортлары;
- балалар бакчалары, мәктәпкәчә тәрбиянең башка объектлары;
- башлангыч һәм урта мәктәпләр;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен.

Рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре:
- аерым тору яки торак йортларга салынган гаражлар яки ачык машина кую урыннары: шәхси участок өчен 2 машина урыны;
- хуҗалык корылмалары;
- бакчалар, яшелчә бакчалар (шәхси ярдәмче хуҗалыклар);
- теплицалар, оранжереялар;
- уен мәйданчыклар;

- шәхси кулланыштагы хайваннарны һәм кошларны тоту өчен корылмалар;
- су саклау өчен махсуслаштырылган резервуарлар;
- су алу өчен скважиналар үсеше, индивидуаль коелар (санитар саклау зонасын оештыру шартларында җир асты суларының саклану дәрәҗәсенә карап 30-50 метрдан да ким булмаган күләмдә);
- индивидуаль мунчалар, ишегалды бәдрәфләре;
- янгыннан саклау объектлары (гидрантлар, резервуарлар, янгынга каршы сулыклар);
- ашламалар саклау өчен мәйданчыклар, компост мәйданчыклары, чокырлар яисә әрҗәләр;
- чүп җыю өчен мәйданчыклар.

Файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләре:
- гомуми мәйданы 150 кв. метрдан артмаган беренче кирәк булган товарлар кибетләре;
- кер юу һәм химияле чистарту пунктлары;
- вакытлыча сәүдә объектлары;
- даруханәләр;
- гомуми мәйданы 600 кв. метрдан артмаган амбулатор-сырхауханә учреждениеләре;
- терлек һәм кош-корт асрау өчен корылмалар (яхшы күршелек мөнәсәбәтләрен үтәү шартларында);
- хайваннар даими асралмый торган ветеринария дәваханәләре;
- спорт мәйданчыклары, теннис кортлары;
- спорт заллары, рекреация заллары; эш вакыты чикләнгән күпмаксатлы һәм махсуслаштырылган клублар;
- бүлекчәләр, милиция участок пунктлары;
- элемтә бүлекләре;
- торак-эксплуатация һәм авария-диспетчерлык хезмәтләре;
- конфессиональ объектлар;
- файдалануның хезмәт күрсәтүче һәм коммерцияле төрләре объектлары алдында парковкалар;
- кәрәзле, радиореле һәм иярченле элемтә антенналары.

Җир кишәрлекләренең чик күләме һәм рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары.

Җир кишәрлекләренең чик күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары түбәндәге таблицаның күрсәткечләренә туры килергә тиеш.

Параметрларның төрләре һәм үлчәү берәмлекләре		Күчемсез милекне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның әһәмияте	
		Аерым торган бер гаиләлек йорт	Блоклы купгаиләле йортта бер гаиләгә торак берәмлеге
Җир кишәрлекләренең иң чик параметрлары			
Минималь мәйдан	кв.м	1000	1000
Максималь мәйдан	кв.м	5000	5000
Урам (керү) фронты буйлап минималь киңлек	м	12	6

Кишәрлекләр чикләрендә рөхсәт ителгән төзелешнең соңгы параметрлары Кишәрлек төзелешенең максималь проценты	%	40,5	55
Кишәрлекнең алгы чигеннән корылмаларның минималь чигенеше (башка күрсәткеч төзелешне җайга салу линиясе белән билгеләнмәгән очракларда)	м	3	3
Кишәрлекнең ян чикләреннән төзелешләрнең минималь чикләре	м	а) 1 - брандмауэр стенасы мәҗбүри булганда; б) 3 - башка очракларда	а) 0 - күрше блокларга кушылган очракларда; б) 3 – башка очракларда
Кипшәрлекнең арткы чигеннән булган корылмаларның минималь чигенеше	м	3	3 (төзелеш эшләрен җайга салу линиясе башкача билгеләнмәгән булса)
Төзелешләрнең максималь биеклеге	м	12	12
Җир кишәрлекләре киртәләренең максималь биеклеге	м	2,0*	1,2*

* Чиктәш участоклар арасындагы материал һәм тип киртәләр, яшелчә бакчалары белән тәэмин ителгән өлештә кояш яктысын үткәрә торган челтәрсыман итеп кабул ителә.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гаражлар төзү һәм урнаштыру, хуҗалык корылмалары төзү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләме түбәндәге таблица күрсәткечләренә туры килергә тиеш.

Параметрларның төрләре һәм үлчәү берәмлекләре	Күчемсез милекне файдалануның ярдәмче һәм шартлы рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның әһәмияте		
	Бакчалар, яшелчә бакчалары (шәхси ярдәмче хуҗалык)	Шәхси гаражлар	Хуҗалык корылмалары
	Җир кишәрлекләренең иң чик параметрлары		
Минималь мәйдан, кв.м	1000	10	10
Максималь мәйдан, кв.м	5000	35	20

Җир кишәрлекләренең билгеләнгән чик (минималь) күләмнәре түбәндәге очракларда кулланылмый:

- җир кишәрлеген хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән һәм мәйданы җир

кишәрлекләренең иң чик (минималь) күләменә туры килә торган җир кишәрлеген җирлектә төзү мөмкинлеге булмау юлы белән җир кишәрлеген барлыкка китерү;

- ике һәм аннан күбрәк җир кишәрлекләрен берләштерү юлы белән җир кишәрлеге барлыкка китерү;

- гамәлдәге күчемсез милек объекты астында төзелә торган җир кишәрлеге барлыкка килү, һәм мәйданы җир кишәрлекләренең иң чик (минималь) үлчәмнәренә туры килә торган җирлектә җир кишәрлеген формалаштыру мөмкинлеге булмау.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш
авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шәрәфетдинов